СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

10. 10. 2025 г.Лениногорск № 13

Махсус хәрби операциядә катнашучы һәм «Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен 14 нче Лениногорск мәктәбе»ДБГББУ дә белем алучы сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар гаиләләренә, Лениногорск шәһәре территориясендә автомобиль транспортында (таксидан тыш), шәһәр җир өсте транспортында җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутлары буенча балаларның түләүсез йөрүе рәвешендә өстәмә социаль ярдәм күрсәтү турында

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында»2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указына таянып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы белән, Лениногорск муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Махсус хәрби операциядә катнашучы һәм «Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен 14 нче Лениногорск мәктәбе»ДБГББУ дә белем алучы сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар гаиләләренә, Лениногорск шәһәре территориясендә автомобиль транспортында (таксидан тыш), шәһәр җир өсте транспортында җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутлары буенча балаларның түләүсез йөрүе рәвешендә, 2025 елның 1 сентябреннән 2025 елның 31 декабренә кадәр, өстәмә социаль ярдәм күрсәтү урнаштырырга.

2. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына махсус хәрби операциядә катнашучы һәм «Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен 14 нче Лениногорск мәктәбе»ДБГББУ дә белем алучы сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар гаиләләренә, Лениногорск шәһәре территориясендә автомобиль транспортында (таксидан тыш), шәһәр җир өсте транспортында җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципаль маршрутлары буенча

балаларның түләүсез йөрүе рәвешендә, өстәмә социаль ярдәм күрсәтү тәртибен эшләргә һәм расларга.

3.Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Финанс-бюджет палатасы» МКУ Лениногорск муниципаль районы бюджетыннан әлеге карарның 1 пунктында каралган максатларга акча табарга.

4.Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар 2025 елның 01 сентябреннән хокук мөнәсәбәтләренә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лениногорск муниципаль районы Советының социаль һәм милли мәсьәләләр, мәгариф, мәдәният һәм яшьләр сәясәте буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Лениногорск муниципаль
районы Башлыгы,
Совет рәисе М.Н.Гирфанов